**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№1** **03.12.2021**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге составына керүче,
Благодатное поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 03 декабрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2022 елда, Микулино авыл җирлеге Благодатное торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кыш көне юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- Щебенка сатып алу һәм Березовая урамы буенча юлны төзекләндерү;
- Щебенка сатып алу һәм Зеленая урамы буенча юлны төзекләндерү;
- Бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү («Сабантуй», «Авыл көне», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел»).

РИЗА КАРШЫ

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 160 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 121 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 121 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

җыенда катнашучы 0 кеше «Юк» позициясе өчен тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге составына керүче Благодатное поселогында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: ««Сез, 2022 елда, Микулино авыл җирлеге Благодатное торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 175 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кыш көне юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);
- Щебенка сатып алу һәм Березовая урамы буенча юлны төзекләндерү;
- Щебенка сатып алу һәм Зеленая урамы буенча юлны төзекләндерү;
- Бәйрәмнәр оештыру һәм үткәрү («Сабантуй», «Авыл көне», «Өлкәннәр көне», «Яңа ел»).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Благодатное поселогы, Солнечная урамы, 7 нче йорт, Садовая урамы, 3а йорт, Зеленая урамы, 1а йорт, Березовая урамы, 1 нче йорт, Лесная урамы, 4 нче йорт.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Микулино авыл җирлеге Башлыгы И.А.Такиулин